1997 елдан нәшер ителә

Әлмәт хәбәрләре

http://almetyevsk.tatar.ru

Әлмәт үсеш узелы: транспорт, икътисади киңлек, бизнес, мәгариф

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов кушуы буенча, "2030 елга кадәр Татарстан Республикасын үстерү стратегисе" проекты эшләнә.

Әлеге эшне "Леонтьев үзәге" халыкара социаль-икътисади тикшеренүләр үзәге (Санкт-Петербург) белгечләре алып бара. Алар фикеренчә, төбәк югары үсеш нәтиҗәсе белән аерылып тора. Моннан тыш биредә чит илләрнең алдынгы тәҗрибәләре өйрәнелә һәм кулланыла Тикшеренүләрнең беренче этабы кысаларында "Татарстан Республикасының глобаль көндәшлеләккә сәләтлелеге", "Кеше. Җәмгыять. Дәүләт", "Авыл җирлеге", "Транспорт-коммуникацион киңлек" кебек тикшеренү юнәлешләре, шулай ук проект буенча киләчәктә эшләү планы һәм графигы тәкъдим ителде инде.

Проектның бер өлеше буларак, 25 январь көнне "Әлмәт үсеш узелы: транспорт, киңлек, бизнес, мәгариф"эзләнү конференциясе узды.

Чарага Азнакай, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы, Ютазы, Чирмешән районнарыннан җирле үзидарә органнары вәкилләре чакырылган иде. Конференциядә шулай ук Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Марат Гирфанов, аның урынбасарлары, идарә җитәкчеләре катнашты.

ТР Икътисад министры урынбасары Айрат Шәмсиев сәламләү сүзе белән чыгыш ясап, чараны оештырырга мөмкинлек булдырганнары өчен Әлмәт районы җитәкчелегенә рәхмәт белдерде, нефтьчеләр башкаласының республиканың социаль - икътисади үсешендә мөһим роль уйнавын ассызыклады. Аның сүзләренә караганда, эзләнү конференциясендә актив катнашып, һәрбер район вәкиле озак сроклы үсешкә нигезләнгән проектка үз өлешен кертә ала.

"Леонтьев үзәге" халыкара социаль-икътисади тикшеренүләр үзәгенең стратегик планлаштыру итү ресурс үзәге директоры Борис Жихаревич билгеләп узганча, эзләнү конференциясе традицион киңәшмәләрдән аермалы буларак, төрле чиндагы җитәкчеләрнең тигез шартларда сөйләшеп, фикер алышуы бу очракта Әлмәт икътисади зонасының киләчәктә нинди юнәлештә үсеш алуын ачыклау булып тора.

Кереш өлештә Санкт- Петербург белгечләре проектның концепциясен, төп юнәлешләрен аңлатып үттеләр. Татарстанның үсеше өчен приоритетлы өлкәләр булып мәгариф, кеше капиталы, милләт һәм динара тигезлек, үсеш киңлеге, сәнәгый һәм агросәнәгый сәясәт санала. Нефтьчеләр башкаласында узган конференциядә өч зур тема: җәмгыять һәм социаль өлкәнең икътисади киңлеге, транспорт һәм мәгариф тикшерелде.

Конференциядә катнашучылар 6 төркемгә бүленеп, төрле темалар буенча экспресс карарлар әзерләделәр. Алар алдына киләсе 15-20 елда шәһәрнең, төбәкнең үсешен күзаллау бурычы куелды. Борис Жихаревич аңлатканча, Татарстан Россиянең башка өлкәләре арасында барлык яктан алдынгы булуы белән аерылып тора. Биредә өч үсеш полосасы: Казан, нефть чыгаручы Әлмәт һәм автомобиль төзелеше белән Яр Чаллы аерылып тора. Ләкин һәрвакыт шулай була алырмы? Нефть, бәлки, озакка да җитәр, ләкин аннан килгән керемне озакка җитәрлек, әлеге средстволар киләчәк өчен дә эшләрлек, өстәмә тармаклар булдырырлык итеп кулланырга кирәк. Тагын бер мөһим мәсьәлә - агломерация. Халыкны, бигрәк тә яхшы белгечләрнең үз туган җирләрендә калуына ирешү. Кешеләр Әлмәттән Казанга, Казаннан Мәскәүгә, аннан чит илгә китәләр. Әгәр дә Әлмәтнең шәһәр буларак үсүен теләсәк, алар биредә калырлык шартлар булдырырга тиешбез. "Нәкъ менә әлеге сорауларга бүгенге конференциядә өлешчә булса да җаваплар табылыр, дип ышанам", - диде ул журналистларга биргән интервьюсында

Чара ахырында төркемнәрдә эшләүчеләр үзләренең проектларын тәкъдир иттеләр

Шундый ук конференцияләр Яр Чаллы һәм Казанда да уздырылачак. Очрашулар барышында тупланган идея һәм фикерләр кабаттан өйрәнелеп, төбәкнең үсеше өчен нигез итеп алынырга мөмкин.

Фәрдия ХӘСӘНОВА

Торак-коммуналь хезмәтләр өчен Интернет аша түләү - заман таләбе

Торак-коммуналь хезмәт һәм аның өчен түләүләр бүгенге тормышның иң авырткан ноктасы, дисәк тә, ялгышмабыз. Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә ышангандa, халыкның 72 проценты әнә шундый фикердә. Аеруча кышкы айларда квартплатаның 3-4, хәтта 6-7 мең сум килүен исәпләсәк, гаиләдәге ике эшләүченең берсе шуның өчен генә хезмәт итәргә тиеш. Халыкның 8 процентын инде иртәгә үк урамга куып чыгарырга мөмкиннәр - алар торак өчен түли алмый. Республикада кулланылган ресурслар өчен бурыч күләме 766,2 млн сум. Әлмәт буенча исә, әлеге күрсәткеч 2014 елның 14 январенә 290 590,5 мең сум тәшкил итә.

Вәзгыятьне аз гына булса да яхшыртыр өчен, халыкның 85 проценты акчасын кысыбрак тотарга тырыша икән: энергияне азрак "ашый" торган лампалар куллана, санагычлар урнаштыра, торакларын җылыта. Акчаны янга калдырыр өчен халыкның 14 проценты антенна, радио, лифттан баш тарткан.

Торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларның күплеге, бәяләрнең зур булуы белән беррәттән, түләнгән средстволарның үз вакытында тиешле службаларга барып җитәмәвенә дә бәйле. Берәүләрнең акчасы булмаса, икенчеләренең озын-озак чиратларда торырга вакыты кысан. Әлеге очракта да тормышыбызның аерылгысыз өлешенә әверелгән Интернет ярдәмгә килә. Статистик мәгълүматлар буенча, "Ачык Татарстан" рәсми порталы аша электрон түләүләр кабул итү буенча Әлмәт муниципаль районы Түбән Кама һәм Яшел Үзән шәһәрләреннән кала өченче урында. Әлмәттә 79 меңгә якын йорт хуҗалыгы исәпләнә, шуның бары тик 25 проценты гына түләүләрне электрон рәвештә башкара.

Бүген фатир, электр энергиясе, телефон, Интернет, кабельле телевидение өчен электрон формада түләргә була. Интернет аша түләүне башкару өчен кулыгызда берәр банкның пластик картасы булырга тиеш. Коммуналь түләүләрне www.uslugi.tatar.ru ТР дәүләт хезмәтләре сайтында башкарырга мөмкин. Шулай ук Әлмәт рәсми сайты **http://almetyevsk.tatar.ru** аша да керергә мөмкин. Әлеге сайтның уң ягында, өске якта Госуслуги (соңгы графа) "Опата за ЖКУ " дигән ячейканы табасыз. Аннары квитанциядә күрсәтелгән ун билгедән торган лицевой номерны һәм түли торган сумманы җыярга кирәк. Шуннан соң түләүчегә үзе турындагы мәгълүматны тутырырга, кайсы банк картасы белән түләүне башкаруын күрсәтәргә кирәк булачак. Әлеге операцияләрдән соң түләүне раслау сорала. Аннан соң банк картагызның мәгълүматларын кертергә һәм түләүне башкарырга кирәк. Шуннан соң экранга түләү турындагы язу чыгуын көтәсе кала. Квитанцияне электрон рәвештә саклау, ә принтер булганда бастырып чыгару мөһим, чөнки ул сезнең түләү турындагы документыгыз. Коммуналь хезмәтләр өчен әлеге ысул белән түләнгән акча якынча өч-дүрт көндә барып җитәчәк.



Өйдән чыкмыйча гына online режимда торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләр турындагы мәгълүматны тикшерергә, лицевой счет белән идарә итәргә, счет-фактурага үзгәрешләр кертергә, һәм, мәсәлән, фатирда берничә көн кайнар су булмаган очракта, исәпләүләрне яңадан башкарырга, түләүләр тарихын электрон рәвештә сакларга була. Моның өчен Порталда «Шәхси кабинет» булдырырга кирәк. Теркәлү бик җиңел - моның өчен мобиль телефон номерын күрсәтергә кирәк, аңа соңрак пароль җибәреләчәк.

Сезнең идарәче компаниягезнең әлеге сервиска кушылганлыгын https://uslugi.tatar.ru/personal-account сылтамасы буенча карарга мөмкин.

Фәрдия ХӘСӘНОВА